СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

« 29 » июль 2020 ел № 343

## Арча муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясына, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы ТР Законына таянып, Арча район Советы карар бирде:

1. Арча район Советының 2015 елның 22 гыйнварындагы 313 номерлы карары белән расланган (28.05.2015 Ел, № 335, 26.10.2015 № 11, 19.02.2016 ел, №9; 2016 ел, 10.11.2017, №150, 23.01.2018 ел, №160, 18.04.2019 ел, №243 үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) Арча муниципаль районы Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1) 6 статьяның 1 өлешендәге 17 пунктына «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган» сүзләреннән соң «, авылара территориядә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү» сүзләрен өстәргә;

2) 6.1 статьяга түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) түбәндәге эчтәлекле 4.1. пунктчасы өстәргә:

4.1) җылылык белән тәэмин итү системасының ышанычлылыгын һәм энергетика нәтиҗәлелеген үстерү өчен кирәкле һәм "Җылылык белән тәэмин итү турында" Федераль законда билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җылылык белән тәэмин итү схемасы буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү чараларын үтәү буенча җылылык белән тәэмин итүнең бәя зоналарында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру";

б) 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) авыл җирлекләренең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, авыл җирлекләренең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру буенча документларны раслау, җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү, төзелешкә рөхсәтләр бирү (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш), авыл җирлекләре территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашырганда объектларны файдалануга тапшыруга

рөхсәт бирү, авыл җирлекләрен шәһәр төзелеше проектлауның җирле нормативларын раслау, муниципаль ихтыяҗлар өчен авыл җирлекләре чикләрендә җирләрне резервлау һәм җир кишәрлекләрен тартып алу, авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда биналарны карап тикшерү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү турында тәкъдимнәр кертү, җир кишәрлегендә шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты төзү яки реконструкцияләү турында (алга таба - планлаштырыла торган төзелеш) һәм җир кишәрлегендә шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру мөмкинлеге, планлаштырыла торган шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларының күрсәтелгән параметрларга туры килмәве һәм (яисә) җир кишәрлегендә шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителмәү турында, төзелгән яки үзгәртеп корылган шәхси торак төзелеше объектының яки бакча йортының җир кишәрлекләрендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе яки туры килмәве, максатчан билгеләнеше буенча кулланылмаган яисә Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган җир кишәрлеген тартып алу турында карар кабул итү турында хәбәрнамәләр җибәрү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда, үзбелдекле төзелгән корылманы сүтү яки аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү, авылара территориядә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү;

3) 30 статьяга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Район Советы депутаты, әлеге Уставта билгеләнгән очраклардан тыш, депутатлык эшчәнлеген төп эш урыны буенча хезмәт һәм эш вазыйфаларыннан азат ителмәгән рәвештә башкара. Район Советы депутатына үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкару өчен эш урынын (вазыйфасын) аена алты эш көненнән артык булмаган вакытка саклау гарантияләнә.».

б) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы район Советы депутаты түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) шәхсән яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) түбәндәге очраклардан тыш, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси партия, һөнәр берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан түләүсез идарәдә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашырга;

б) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе

субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәр итеп, түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының гомуми җыелышында (конференция) катнашудан тыш);

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итәргә;

г) муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә, гамәлгә куючысы (акционер, катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә итү органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итәргә;

д) федераль законнарда каралган башка очракларда;

3) мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый;

4) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясе территориясендә эш итүче хөкүмәткә карамаган коммерциячел булмаган чит ил оешмаларының һәм аларның структур бүлекчәләренең идарә органнары, попечительләр һәм күзәтүчеләр советлары, бүтән органнары составына керергә;

5) муниципаль вазыйфаны биләп торучы һәм үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы зат, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 40 статьясындагы 7 өлешенең 2 пунктындагы «б» пунктчасында һәм «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 3.5 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында каралган очракларда, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Президентына алдан хәбәр итеп, коммерциячел булмаган оешмалар белән түләүсез идарә итүдә катнашырга хокуклы.

в) 6.2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларны саклауны, чит ил

финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон, 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон белән билгеләнгән «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясының 7_2 нче өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү фактлары ачыклангада, Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) җирле үзидарә депутатының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә депутатка карата башка җаваплылык чарасы куллану турында тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка гариза белән мөрәҗәгать итә.

г) түбәндәге эчтәлекле 6.2.1. пункт өстәргә:

«6.2.1. Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган мәгълүмат биргән җирле үзидарә депутатына карата, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып күрсәтү артык әһәмиятле булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында вәкаләтләр биләү хокукыннан мәхрүм итеп, вәкаләтләре срогы тәмамланганчы вазыйфасыннан азат итү;

3) даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итеп, вәкаләтләре срогы тәмамланганчы даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашырудан азат итү;

4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында вазыйфалар биләүне вәкаләтләре срогы тәмамланганчы тыю;

5) даими нигездә вәкаләтләрен үтәүн вәкаләтләре срогы тәмамланганчы тыю»;

д) түбәндәге эчтәлекле 6.2.2. пункт өстәргә:

«6.2.2. Җирле үзидарә депутатына «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7_3-1 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә».;

е) 8 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законда, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм

45

башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларны саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәгән очракта вакытыннан алда туктатыла.»

4) 88 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"88 статья. Муниципаль финанс контроле

1. Муниципаль финанс контроле бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган хокукый актлар, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан физик затларга бүтән түләүләр буенча гавами норматив йөкләмәләр һәм йөкләмәләр, шулай ук дәүләт (муниципаль) контрактлары, шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәүне тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла.

Муниципаль финанс контроле тышкы һәм эчке, башлангыч һәм чираттагы төрләргә бүленә.

2. Тышкы муниципаль финанс контроле-җирлекнең Ревизия комиссиясенең контрольлек итү эшчәнлеге.

3. Эчке муниципаль финанс контроле-җирлек башкарма комитеты органнары (вазыйфаи затлары) булган муниципаль финанс контроле органнарының контрольлек итү эшчәнлеге.

4. Башлангыч финанс контроле җирлекнең җирле бюджетын үтәү барышында бюджет бозуларны кисәтү һәм булдырмау максатларында башкарыла.

5. Чираттагы финанс контроле җирлек бюджетының үтәлеше нәтиҗәләре буенча аларның үтәлешенең законлылыгын, исәп-хисапның дөреслеген билгеләү максатыннан башкарыла.».

2. Әлеге карарны «Арча хәбәрләре» район газетасында яки Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе — И.Г. Нуриев